| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЬ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 671 «11» декабрь 2025 ел

«Муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 02 июлендәге 406 номерлы карары белән расланган административ регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарына, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 октябрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнарына, «Бердәм санлы платформа «Территориаль мәгълүматларның милли системасы» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 7 июнендәге 1040 номерлы карарына, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы законына нигезләнеп, ТР Спасск муниципаль районының Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «муниципаль милектәге җирләрне һәм (яисә) җир кишәрлекләрен һәм хосусый милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 02 июлендәге 406 номерлы карары белән расланган административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3.5.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында Пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген

тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы бер эш көнен тәшкил итә.»;

1.2. 3.5.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.5. Регламентның 3.6.2.1-3.6.2.2 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.6.2 - 3.6.4 пунктында күрсәтелгән, шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында Пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Регламент пунктында күрсәтелгән административ процедураларны үтәүнең максималь срогы 17 эш көне тәшкил итә, җир кишәрлеге биреләчәк дигән хәбәр басылып чыккан очракта-49 эш көне».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р. Р. Закировка йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы М.В. Шеронов